ТАТАРСТАН
ВЕТЕРАНЫ

№ 5
3 май,
2023 ел

ВТ

Җиңүгә – 78 ел

РЕСПУБЛИКА ВЕТЕРАННАРЫ (ПЕНСИОНЕРЛАРЫ) ТӨБӘК ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ СОВЕТЫ ҺӘМ «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНЫҢ УРТАК КУШЫМТАСЫ

БӘЙРӘМ БЕЛӘН!

Автор фотосы

БӘХЕТЛЕ ГОМЕР

Апас

Түбән Барыш авылында яшәүче, озак еллар мәдәният өлкәсендә хезмәт иткән, бүген дә мәдәни тормыш белән кызыксынып, киңәшләрен биреп, иҗаттан аерылмыйча яшәүче Фирүзә апа Закирова бу көннәрдә 90 яшьлек олы юбилеен каршылады.

Фирүзә апа тумышы белән Башкортстан якларыннан. Яшьлегендә апасына кунакка килгән кыз Апаста төпләнеп кала. «Клубка кеше тапканчы гына», – дип эшкә кергән яшь хезмәткәр гомерлеккә калуын сизми дә.

Фирүзә апа 30 елдан артык мәдәният өлкәсендә хезмәт итә. Ул чакларны сагынып искә ала ул. Җор телле, сүзгә тапкыр үзе. Хәзер дә шигырьләр иҗат итә, аларны дәфтәр битенә теркәп тә куя. Иҗат җимешләрен матур итеп яттан сөйли. Республика, район хәбәрләре белән танышып бара. Туганнарын, якыннарын барлап кына тора. Балалары, оныклары, оныкчыкларыннан зур игътибар тоеп яши.

– Мин гаиләдә сигезенче бала идем. Абый-апаларны тыңлап үскәнгә, эшкә чакыруны да җитди кабул иттем. Яшьләр күп. Кечкенә генә клубның эче буш. Салкын клубны җылыту өчен, чи утын яга идек. Шулай да, концертлар, кечкенә өзекләр куйдык. Сәхнә өчен үзем дә эчтәлекле скетчлар яздым. Күңелле яшәдек, авырлыкларны көр күңелебез белән җиңдек, – ди әбекәй.

Фирүзә апа үзе лаеклы ялга чыкканда эшен ышанычлы кулларга – кызы Кәүсәрия апа Мостафинага тапшыра.

– Әни еррактан килсә дә, Түбән Барыш авылын, аның кешеләрен яратып, хөрмәт итеп яшәде. Тормышта тиң ярын – әтиебез Нурулланы да биредә очратып, озын матур гомер кичерделәр. Әнидән клуб ачкычын алганда миңа 24 яшь кенә иде. Ул минем таянычым, ярдәмчем булды. Әнинең эшен 32 ел дәвам иттердем, – ди Кәүсәрия апа.

Фирүзә апа 5 балага гомер бүләк иткән. Кызганыч, улын вакытсыз югалткан. Бүген 9 онык, 12 оныкчыкның ихтирамын тоеп, кызы Гүзәл тәрбиясендә гомер итә.

– 18 елдан бирле әни янәшәсендә мин. Әни әле ашарга да пешереп куя, тик утырырга яратмый. Авылдагы туганнарга да барып килә. Хәлләрен белеп кайта. Үзен кайгырта, вакытында даруын да эчә. Туган йортта барыбыз да җыелабыз. Әни барыбызны бер йодрыкка җыеп тора, – ди Гүзәл апа Миңнуллина.

Туганнары, якыннары Фирүзә апага «тәти апа» дип эндәшә. Көн тууга хәлен белешәләр.

– Тәти апа кешелекнең иң яхшы сыйфатларын үзенә туплаган. Килендәше белән апалы-сеңелле кебек яшәделәр. Елның кайсы вакытында кайтсак та, аның йөзе ачык, матур итеп елмаеп, якын итеп, туган итеп каршы ала, – ди туганнары Гөлфара апа Закирова.

Фирүзә апага район башлыгының котлаулары юлланды. Район башкарма комитеты хезмәткәре Ринат Гыйльфанов иң изге теләкләрен җиткерде һәм бүләкләр тапшырды. Зур Күккүз авыл җирлеге башлыгы Рузия Низамова, районның үзәкләштерелгән клублар системасы җитәкчесе Роза Нурмиева хөрмәтләде, зурлады үзен.

– 90 ел сизелми дә үтеп киткән. Үткәннәр якты хатирә булып истә калган. Бүген мин бик бәхетле. Кадерле әни, дәү әни булып яшим, – ди ул.

Ләйлә ШИҺАБИЕВА

ТОРМЫШ КҮГЕ КОЯШЛЫ ҺӘМ АЯЗ БУЛСЫН!

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хөрмәтле ветераннар!

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасының республика советы исеменнән, шәхсән үз исемемнән сезне иң кадерле һәм иң тантаналы бәйрәм – 1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышында Җиңү көне уңаеннан чын күңелдән котлыйм!

Европаны коллыкка төшерүгә омтылып, дистәләрчә миллион кешегә иксез-чиксез михнәт-газап китергән фашизм моннан 78 ел элегрәк, сугышчы-фронтовикларның батырлыгы һәм каһарманлыгы, тыл хезмәтчәннәренең ныклыгы һәм түземлеге белән, тар-мар ителде.

Җиңү җиңел бирелмәде. Күпме ир-атлар яу кырында ятып калды. Беркайчан да онытылмаячак бу! Шуңа күрә 9 Май – миллионнарча кешенең күңелендә аерым урын алып торган изге бәйрәм.

Бөек Ватан сугышы кагылмаган бер генә гаилә дә юк. Аларның һәркайсының – үз герое. Җиңүче сугышчылар һәм тылда җиңүгә өлеш кертүчеләр, үзләренең гомере бәрабәренә Ватаныбызны фашизмнан коткарып калучылар истәлеге төрле буыннарны берләштерә. Бүген бу бердәмлек теләсә кайсы куркыныч-янауларга каршы тору өчен, Россиянең бөек, көчле һәм нык үсешле булуы өчен барын да эшләүгә көч-куәт бирә.

Кызганыч, нацизм бүген дә баш күтәреп, үзенең вәхшилеген, кешелексезлеген җәелдерергә омтыла. Безнең изге бурыч – Бөек Ватан сугышында җиңелгәннәрнең дәвамчыларына үч алуга юл куймау. Европаны фашизмнан азат иткән солдатларның оныклары һәм онык балалары хәзер илебез мәнфәгатьләрен, аның мөстәкыйльлеген, киләчәк тормышка хокукын яклый-саклый. Татарстан ветераннары уртак җиңүебезне якынайту өчен тырыша: һәр районда Украинада махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләребезгә, аларның гаиләләренә, шулай ук Россия составына кергән шәһәрләрдә яшәүчеләргә ярдәм итү буенча зур эш алып барыла.

Бу көнне без Ватаныбызның киләчәге хакына үзләренең гомерен дә кызганмаган солдатларның якты истәлеге алдында баш иябез. Безгә тормыш бүләк итүчеләрнең истәлеген кадерләп саклыйбыз. Һәрбер авылда, һәрбер шәһәрдә нацизмны җиңүчеләр хөрмәтенә мемориаллар калкып чыга. Һәр елда, Россия халкының какшамас ихтыярына гимн сыман, бу монументлар өстендә аяз күк ачыла.

Кадерле ветераннар! Сез илебезнең, республиканың мөмкинлекләрен үстерү өчен бик күпне эшләп, бүген дә зирәклегегез, тормыш тәҗрибәгез белән бик теләп уртаклашасыз һәм әле һаман сафта булырга, җәмгыятькә файда китерергә омтылып яшисез. Сезне Бөек Җиңү көне белән котлыйм!

Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер, тынычлык һәм иминлек телим! Һәрвакыт туганнарыгыз һәм якыннарыгыз янәшә, ә тормыш күге аяз һәм кояшлы булсын! Барыбызга да тыныч күк йөзе һәм гадел киләчәк телим!

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе Х.Г. ИШТИРӘКОВ

ЭЗЛӘП ТАБАРМЫН СИНЕ, ӘТИ

Казан

Язга чыктыңмы, хатирәләр яңара. Бөек Ватан сугышы фаҗигасе, язмышлар тынгысызлый, төн йокыларын ала. Уйласаң, уелыплар китәрлек бит: әти сугышка киткәндә, әнигә – 28, миңа – 6, энекәшләргә 4 һәм 2,5 яшь иде.

Әле дә күз алдында: иртән мине чәйгә уяттылар, гадәттәгечә әти янына утырдым. Әни нишләптер елый да елый, әти аны тынычландырырга тырыша. «Ике атнадан мине кире кайтаралар, Кызыл Армиягә авыру ирләр кирәкми», – ди. Узган елны ул бик каты авырган иде шул. Тракторист булып эшли иде, аннан да китәргә мәҗбүр булды. Шулай борчу катыш чәй эчтек тә, әти кузгалырга вакыт дип җыена башлады. Мин әтине озата бардым, әни капка төбендә калды.

Әти мине җитәкләп бара, үзе миңа сөйли: «Син хәзер зур инде, ир кеше, әниеңне тыңла, аңа булыш, энеләреңне тәрбияләү синең өстә, башкалардан кыерсыттырма, якла...» Безнең авылның өч урамы бер мәйданга килеп тоташа. Мәйданда кибет, клуб, кое, канцелярия һәм башка биналар бар. Мәйдан кырыенда җиккән ат тора, әти капчыгын арбага салды да, без башкаларның җыелганын көтә башладык. Мин әтинең биштәре янына менеп утырдым. Берзаман сугышка китүчеләр җыелды. Әти мине күтәреп алды да, бик каты күкрәгенә кысып, кибетнең баскычына алып барып бастырды:

– Без күренми башлагач, өйгә кайтырсың, яме.

Күзләрендә яшь иде. Кем уйлаган шунда әтине соңгы тапкыр күрәм дип. Кузгалдылар. Алдан ат бара, 10 кеше урамны иңләп кулларын атка куеп тизелешеп китеп бардылар. Бераздан әти, каерылып, миңа карады.

Шул көннән башлап әти бастырган баскыч тактасы минем өчен бер изге урынга әйләнде. Кибет янышнан узган саен һәрвакыт йөгереп барам да, шул ноктага басып, әтиләр киткән юлга карап торам. Мәктәпне тәмамлап, авылдан киткәч тә, кайткан саен иң элек шунда барып килә идем. Олыгайгач тагын кайттым шул баскыч янына, тик кибетне сүткәннәр иде. Шул чакны әтине тагын бер мәртәбә югалткандай булдым.

Әтине бик сагына идек. Ул да сагынгандыр: әни хатларын кычкырып укый иде. Әти язган шигырьләр гомерлеккә күңелгә уелып калды:

Бер әйләндем, ике әйләндем,
Ленинград каласын.
Бар кеше дә минем кебек
Сагына микән баласын?..
Нива елгасына төшеп,
Юамын кулларымны.
Бәгырькәем, сагынам сине,
Сагынамын улларымны!

Ә бит тыныч вакытларда да әти өйдә бик тансык кеше иде. Без аны бик сирәк күрдек. Ул вакытта тракторлар МТС карамагында булып, әтиләр кыш буе шунда ремонт ясыйлар, ә язын аларны үзебезнең авылга түгел, ерак авылларга эшкә җибәрәләр иде. Кыш көне ике айга бер кайтса, җәйләрен без аның белән бөтенләй күрешми идек. Юкса МТС бездән 15 км ераклыкта гына урнашкан.

1942 елның ахырларында әтинең хатлары килми башлады. Әни моңа бик борчыла, ләкин безгә сиздермәскә тырыша. Без дә сер бирмәскә тырышабыз, ә минә кечкенә энекәш бик сагына иде. Әни, бәгырь, ничек түзгәндер. Сугышның бөтен вәхши авырлыгы: кеше башкара алмаслык авыр, исәпсез эше, ачлык, ялангачлык, төрле түләүләр хатын-кыз җилкәсенә төште. Без, балалар да, беркемгә кирәк түгел идек, әниләрдән башка кайгыртучы, ярдәмче юк иде. Балачак әнә шулай үтте.

vk.com

7 класс бетергәч, мин Казанга киттем. 1954 елның көзендә армиягә алдылар. Армиядә яхшы замполитлар бар иде ул вакытта. Майор Бабанин әтинең хәбәрсез югалганын белгәч, эзләтеп карарга киңәш итте. Аның ярдәме белән төрле оешмаларга «запрос»лар ясадык. Германиянең үзәк хәрби архивына да мөрәҗәгать иттек. Хәрби әсирләр комитетына да. Икесеннән дә «кайда икәнлеге билгеле түгел» дигән җавап килде. Тукталып калмадым, армиядән кайткач та шушы юнәлештә эзләнүне дәвам иттердем. Сораша торгач, әти белән сугышкан 15ләп кешене эзләп таптым. Алар кыр почтасы номерын, кайда сугышканнарын әйттеләр. Валдайда булганнар икән. Әйтүләренчә, 1942 елның ноябрь аенда төнлә тревога белән күтәреп, аларны аерым алып чыгып китәләр. Шунда эзләнүләр өзелә.

Ниһаять, 1994 елда хәбәр килде. Новгород өлкәсендә, туганнар каберлегендә күмелгән икән. Шул урынны 2016 елда таптым, хат язып, 9 Майга килсәк буламы, дип сорадым. Баксаң, сазлык җирләр, яз айларында анда йөреп тә булмый икән. Инде уңайлырак вакытны белешкәч, 2017 елда улым, кызым, киявем белән әти күмелгән каберне зиярәт итеп кайтулар насыйп булды. Безне бик әйбәт каршы алдылар, озатып йөрделәр. Башта моторлы көймә белән ярты сәгать чамасы йөздек, аннан соң җәяү урман эченнән дүрт чакрым сазлыклар арасыннан бардык. Берниндиюл, сукмак юк. Анда йөрүче дә юк икән. Безне озатып баручының кулында озын таяк иде, сазлыклардан алып барып җиткерде. Немец бомбасы төшкән чокырга бөтен мәетләрне җыеп күмгәннәр. Туганнар кабере менә шул икән. Әйләнәтирәсе тотылган, чиста-пөхтә үзе. Сугыштан соң табылган мәетләрне дә һаман шунда күмәләр. Каберлектә татар исемнәре бик күп. Администрация башлыгы урынбасары белән дә сөйләштем. 2016 елда 2000 солдатның җәсәден җыеп күмгәннәр. Шулардан 38 медальон чыккан. 17се укылырлык хәлдә булып, аларның икесе – татар кешесе. Ә калган 1983 солдат хәбәрсез югалган исәбендә...

Нәсих ШӘЙХЕТДИНОВ, 88 яшь

РӘХӘТ ТОРМЫШ КАРТЛЫККА КАЛГАН

Апас

Лагерканың иң өлкән кешесе Клавдия Мишкинаның күзлеге бөтенләй юк, ул аңа кирәкми дә. 95 яшьлек ветеран әле дә бәйли, тегә, җырлап юана.

Алдан белешкән адрес буенча аларның өй каршына килеп туктадым. Ишегалдында йөрүче берәүдән Клавдия Павловна турында сорашам.

– Мин булам бит инде ул. Менә кунаклар көтәм, – диде ул. Аңа 95 яшь тулган дип кем әйтер?!

Без килгән көнне бу өйдә бик иртә торганнар. Клавдия Павловнаның Кама Аланында яшәүче кызы Татьяна Николаевна духовкага чуаш милли ризыгы – итле-бәрәңгеле хуплу пешерергә куйган. Аның тәмле исе болай да чиста, җыйнак кына 100 еллык өйләренә нур өстәгән сыман. Читтә яшәүче улы Владимир яңашәдә ике катлы яңа йорт та өлгерткән, тик әниләрен анда торырга күндерә алмыйлар икән.

– Күнеккән урында рәхәт, җәннәттәге кебек, – ди әбекәй. – Тормыштан зарланмыйм, балаларым бик яхшы, шуңа да озын гомерле булдым. Әле дә күзлек кимим, рәхәтләнеп телевизор карыйм. Тирә-күршенең дә хәлен белешкәлим.

Кышын Клавдия Павловнаны балалары үз яннарына, Кама Аланына алып китәләр икән, язын монда кайтаралар.

– Әни эштән туймады, – ди кызы Татьяна Николаевна. – Фермада маллар карады, колхоз эшенә дә йөрде. Гел сыер асрады, соңрак кәҗәбез бар иде. Әтиебез иң олыбызга 19 яшь чакта вафат булды, шуңа күрә әни урманда агач әзерләп тә нужаланды.

Аларның күбесе онытылган диярлек, Клавдия әбекәй дә элеккеге елларны искә алмады. Әнә бүген нинди рәхәт! Мәскәүдә яшәүче оныгы Ирина, заказ биреп, яраткан әбисенә алдагы көндә иртүк чәчәк бәйләме китерткән.

Клавдия Мишкина әле дә кул эше тота. Ире бүләк иткән тегү машинасына да тузан кундырмый. Әнәне дә күзлексез саплый. Бу көннәрдә тагын бер эш кузгаткан – улына оекбаш бәйли. «Авырлыгы юк, бер кич утырыда бәйлим дә куям», – ди ул.

– Әниебез – горурлыгыбыз, – ди кызы Татьяна. – Исән генә булсын. Җәй айларында монда еш кайтабыз. Оныклар өчен дә әбиләре булу – зур бәхет.

Элек туган көнен дә уздырмаган ул. 8 Мартта да ял итмәгән. Эш калдырырга ярамый, янәсе. Аның каравы картлыгында матур яши. Күпме генә авырлык күрсә дә, рәхәт тормыш өчен сөенеп туя алмый. «Бар бәхетем картлыгыма калган икән», – ди ул.

Кадыйр ГОМӘРОВ

Автор фотосы

БАБАМНЫҢ МЕДАЛЬЛӘРЕ

Бабамның медальләре күп,
Яңа костюмы тулы.
Тик бабамның – разведчикның
Терсәктән юк сул кулы.

Батырлыгы өчен аңа
Унлап медаль биргәннәр.
Алар шул куркак булмаган,
Разведкага йөргәннәр!

Немецлар тылына кереп,
«Тел» алып кайткан чакта,
Бомбалар шартлап ярылган
Туктаусыз алда, артта.

Менә шунда яраланган
Бабамның сыңар кулы.
Таза чакта ничә тапкыр
Айкаган немец тылын.

Ерак елларда булган ул,
Бик күп шәһәрләр алган!
Яңа батырлыклар эшләп,
Медальләр тага барган.

Мин сокланып карыйм аңа,
Баһадир безнең бабай!
Әмма үзе бик аз сузле,
Мактанмый бер дә алай.

Самат ШАКИР

СУГЫШ ЯЛКЫНЫ

Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,
Соңгы тапкыр кояш балкыды.
Таң атмады бүген, таң атмады, –
Алды җирне сугыш ялкыны.

Үлем килде Җир шарының
Кояш баткан ягыннан.
Ватан өчен утка кердек
Сабантуй мәйданыннан.

Томырылды атта яшь егетләр…
Гомер буе көтәр чын ярлар.
Янса янар, әмма Берлингача,
Берлингача атлар чабарлар.

Европада – канлы Сабан туе,
Җирдә бүген – ялкын, көл исе.
Җиңү байрагыдай янып калды
Сабантуйның биек сөлгесе.

Разил ВӘЛИЕВ

ҖИҢҮ КӨНЕ ҖИҢЕЛ БИРЕЛМӘДЕ…

Яшь каеннар яфрак ярган чакта,
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә салып,
Утка төренеп, яуга керделәр.

Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк елый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!

Тарих шаһит: үлмәс Карбышевлар
Әверелә бозга – ил сатмый.
Татар улы – батыр Газинурлар –
Күкрәкләре белән ут каплый.

Яңгыра, җыр, газиз илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

Мансур ШИҺАПОВ

Зәй



Сугыш ветераны Леонид МАЧТАКОВ:
– Җиңү җиңел бирелмәде. Яшь булсак та, Ватан өчен кулга корал алдык. Без җиңүне миллионлаган корбаннар бәрабәренә, илебез халкының бердәм булуы нәтиҗәсендә яуладык. Сугышка мин 1942 елда пехота училищесын тәмамлаганнан соң килеп кердем. Сталинград, Мәскәү янында барган сугышларда, Украинаны фашистлардан азат итүдә, «Курск дугасы» операцияләрендә катнашырга туры килде. Ике тапкыр яраландым, берничә тапкыр чолганыштан чыктым. Днепрны кичкәндә бата яздым. Аллага шөкер, исән калдым.

Сугыш ветераны Анна МОИСЕЕВА:
– Җиңү көнен түземсезлек белән көтәм. Какшаган сәламәтлегемне ныгытканнан соң Җиңү парадына чыгачакмын. Йөз яшемне тутырдым. Бу көннәрне күрә алуыма бик сөенәм. Инде бәйрәм белән котлый башладылар. Район башлыгы Рәзиф Кәримов та котлады. Аның белән бергә «Уймак кыз» балалар бакчасыннан кечкенә Арина Савгильдина да килде. Ул миңа шигырь сөйләде. Сугышка 1942 елда киттем. Без берничә кыз хәрби комиссариатка барып, фронтка алуларын сорадык. Сугыштагы хәлләрне гомер буе онытмадым. Фашистлар берәзлексез бомбага тота, җирне тетрәтеп танклар килә. Кая туры килә, шунда качтык. Мин 473 нче кыр-хирургия госпиталенә эләктем һәм шул госпиталь белән Берлинга кадәр барып җиттем. Бик еш салкын канлы, батыр булырга кирәк, башкача булмый иде. Андагы кан, газап, мәхшәр, үлем…

Госпитальдә дә үзебез сакладык, үлгән яралыларны да үзебез җирләдек. Сугыш барган урыннар хәрабәләрне хәтерләтә, мич морҗалары гына тырпаеп кала иде. Үлгәннәр тиешенчә җирләнми, җир астыннан күренгәннәре шактый. Аларны казып алып, кесәләрендәге жетоннардан кем икәнен ачыклап, гаиләләренә, частена хәбәр итәргә дә туры килде. Берлинга барып җитеп, имзамны Рейхстагта калдырдым. Җиңү шатлыгының чиге булмады, тик ул югалтулар катыш иде. Тыныч тормышка, тыныч эшкә, һай, нык сусаган идек.

Сугыш ветераны Валентина ЛЫКОВА:
– Июль аенда 100 яшем тулачак. Бөек Җиңү бәйрәмен ел да көтеп алам. Быел сәламәтлегем какшап китте, парадка чыга алмам инде. Сугыш афәтләре әле дә истә. Онытырлык булмады шул аларны. Дошманга каршы хатын-кызлар да сугышты. Илгә куркыныч янаганда, ничек инде качып ятасың? Без күпне күрдек, күпне кичердек. Яшь буынга андый хәсрәтләр килмәсен. Илгә-көнгә тынычлык иңсен!

Эштә узган гомер

Әгерҗе

Кырындык авылында яшәүче районның Мактаулы гражданины Суфия Муллахмәтова: «Ходай миңа эш бәхете бирде», – ди. Әйтерлеге дә бар: аның хезмәт стажы – 63 ел.

Байсар авылында туган Суфияның әтисе сугыш кырында ятып кала. Әнисе авыру булганлыктан, кызга башлангыч мәктәпне тәмамлагач та эшли башларга туры килә. Унөч яшендә генә булса да, эшкә батыр була ул. Сарыклар да карый, сыер да сава. Кырынды егете Рафаил белән гаилә коргач та, яраткан эшенә – фермага сыер саварга килә.

– Миңа 25 сөтлебикә тапшырдылар. Тәҗрибәле сыер савучылардан калышмаска тырыштым. Ул чорда сыерларны көнгә өч тапкыр кул белән саудык. Ашату-эчертү, тирес түгү дә кул көче белән башкарылды, – дип элекке хезмәт елларын искә ала Суфия апа.

Кырык ике ел сыер сава авыл уңганы. Лаеклы ялга чыккач та эшләвен дәвам иттерә. 76 яшенә кадәр амбарда эшли.

– Тыйнак, тынлаучан, эшкә батыр Суфия апага хас тагын бер сыйфат – сабырлык. Каенанасына – әйбәт килен, иренә – ипле хатын, балаларына тормыштан ямь, эштән тәм табып яшәүнең гүзәл үрнәге булды ул. Чәкчәк, бәлешне бик тәмле пешерүче бик уңган хуҗабикә дә. Бак-

часында күп итеп яшелчә һәм җиләкҗимеш үстерә, тик торуны белми торган тынгысыз зат, – диләр аның турында кырындылылар.

Илле ике ел бергә яшәгән җәмәгате вафатыннан соң ялгызы гына гомер кичерә. Улы һәм кызларының, биш оныгының, биш оныкчыгының матур тормышларына сөенеп туя алмый. Газеталардан яңалыклар белән танышып бара, телевизордан татарча тапшыруларны яратып карый Суфия апа.

– Авылдашларымның, җитәкчеләрнең хөрмәтен һаман тоеп яшәү бик рәхәт, – дип, илгә-көнгә иминлек теләп, булганына шөкер итеп яши хезмәт ветераны.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА

БИЛГЕСЕЗ СОЛДАТ

Һәйкәл тора. Имеш, сөйлиләр,
Бу – билгесез солдат һәйкәле.
Билгесезме шушы бакыр кеше?
Билгесезме, хәтер, әйт әле?!
Атакага күтәрелдек бергә,
Ега сукты әҗәл бер мәлне.
Вакытлыча янә терелдем мин,
Ул мәңгелек сынга әйләнде.
Каршысында түтәл-түтәл гөлләр
Изге ялкын булып яналар,
Баш өстендә таңнан кошлар сайрый,
Әргәсендә сайрый балалар.
Ә артында аның чал бер хатын
(Ил әнисе – улдыр, мөгаен.)
Ничәмә ел инде өнсез елый,
Салкын ташка бәреп маңгаен.
Җиңү! Кояш балкый бер битендә,
Бер битендә – моңсу ай һаман.
Бер күзеңнән шатлык нуры сибелә,
Бер күзеңнән әче яшь тама…

Мостай КӘРИМ

МИНЕМ БАБАЙ

Минем бабам – капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.

Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,

Көрәшкән чакта бабам,
Әни
Нәкъ минем яшьтә булган,
Рәсем ясап, хат язып,
Бабама салып торган.

Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан!

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Минем бабай орденнарын,
Медальләрен такты бүген.
Ялт-йолт итеп тора алар –
Шуңа күрә якты бүген!

Бүген бигрәк егетләрчә,
Солдатларча атлый бабам.
Бабам белән, җитәкләшеп,
Мин парадка бүген барам.

Җиңүчеләр кебек итеп
Атлыйм мин дә, атлый ул да.
«Син – батыр!» – дим мин бабама,
«Син – батыр!» – дип мактый ул да.

Ул иң батыр солдат булган,
Мин дә солдат булачакмын.
Бабам тыныч ял итсен дип,
Ил чигендә торачакмын!

Борчылмагыз! Үсеп килә
Батырларның оныклары.
Бабайларның батырлыгын
Бер малай да онытмады.

Иртә тусам, мин үзем дә
Бабам кебек булыр идем…
Тынычлыкның туган көнен
Бәйрәм итә бүген илем!

Роберт МИҢНУЛЛИН

ТАТАРСТАН ВЕТЕРАНЫ
Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы советы
һәм «Ватаным Татарстан» газетасының уртак кушымтасы.
Чыгарылыш өчен җаваплы – **Гөлгенә ШИҺАПОВА**. Биткә салучы һәм бизәүче – **Фәрит ХӘМИДУЛЛИН.**
Безнең адрес: Казан шәһәре, Театр урамы, 5 й.
Телефон: 8(843) 238-16-88
Электрон адрес: soovp.kzn@tatar.ru

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ НИКОЛАЙ ПЕТРОВ (АКСУБАЙ РАЙОНЫ):

– Сугышка алынгач, ярты ел санинструкторлар мәктәбендә укыдым. Якташыбыз маршал Толбухин җитәкчелегендәге 3 нче Украина армиясенең 1 батальоны составында идем. 1944 елның август ае кичендә, сәгать сигезләр тирәсендә безнең гаскәрләр һөҗүм итә башлады. Мондый зур сугышта беренче тапкыр катнашуым иде. Мин «Амфибия» бронетранспортерында солдатларны икенче ярга күчердем. Күп кенә дусларым батып та калдылар. Күбесен Румыния чигендә югалттык. Балатон күле янындагы сугышта авыр яраландым. Ядрә кыйпылчыклары башымны һәм берничә урында умыртка баганасын каты яралаган иде. Полк табибы мине тормышка кире кайтарды. Өч ай Турну-Северинск госпиталендә дәваландым. Сугыш беткәнне Медлинг шәһәре янында ишеттек. Туган якка 1950 елда гына кайта алдым. Ул елларны искә төшереп, күкрәгемне «Батырлык өчен» һәм «Хәрби казанышлар өчен» медальләре бизи.

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ ГАЙНУЛЛА ӘЮПОВ (АЗНАКАЙ РАЙОНЫ):

– 1940 елның чатнама суык 19 гыйнварында, солдат шинеле киеп, Ерак Көнчыгышка киттем. Хәрби чыныгуны шунда алдым. Бөек Ватан сугышы башлангач, бер ел Амур елгасы буенда ил чиген японнардан сакладык. Шуннан соң, хәрби техникалар белән платформаларга төялеп, Мәскәүгә юл тоттык. Аннан инде туп-туры фашист бәкрасында калган Сталинградка җибәрделәр. Без, шоферлар, фронтны беренчел кирәк-ярак: хәрби корал, азык-төлек белән тәэмин иттек. Төнлә, караңгыда гына юлга чыгабыз. Фаралар утын шәйләүгә, дошман ата башлый. Ә инде кире кайтканда арбага яралыларны салабыз. Аларны тылдагы госпитальләргә таратабыз. Хәрби бәрелешләрдә күрсәткән батырлыкларымны Кызыл Йолдыз ордены, күпсанлы медальләр белән бәяләделәр. Сталин фәрманы нигезендә часть командиры имзалаган Рәхмәт кәгазьләре генә дә дистәдән артык. Алар Кюстрин, Кишинев, Сохачев, Скерневицы, Ловин, Гнезно шәһәрләрен фашистлардан азат итүдә, Висла елгасының көнбатыш яры буйлап барган бәрелешләрдә, Бранденбург провинциясенә, Германия җиренә үтеп керүдә, Берлинны алу өчен барган сугышларда катнашып, кылган батырлыклар өчен бирелгән.

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ РӘҮФ ТӨХФӘТУЛЛИН (БУА РАЙОНЫ):

– Сугыш башланганда, Белоруссиядә идем. Җиңүдән соң да тиз генә туган якларыма әйләнеп кайта алмадым. Сугышта бик каты яраландым. Терелгәч, үзем теләп, Сталинградка киттем. Аннан мине Горький шәһәренә эшкә җибәрделәр. Мине яшь солдатлар әзерләү өчен танк батальонына билгеләделәр. Берничә тапкыр фронтка җибәрүләрен дә сорадым, әмма каршы килделәр. «Булачак танкистлар әзерләү – ил өчен җитди һәм кирәкле эш», – дип, кире күндерделәр. Җиңүгә үз өлешемне кертүемә сөенеп бетә алмыйм. Аллаһы Тәгалә гомеремне дә бирде. 103 яшемне тутырдым. Җиңү көнен түземсезлек белән көтәм. Илләр тыныч булсын иде!

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ ГАБДРАХМАН САФИН (АРЧА РАЙОНЫ):

– Армиягә 1941 елның 10 августында киттем. Башта безне, Арчадан киткән дүрт егетне, Саратовка җибәрделәр. Анда әзерлек үттек, кыш көне палаткада торып, землянкалар казыдык. Аннары барыбызны да мотострелковыйга күчереп, Сталинград фронтына җибәрделәр.

Без барып урнашканның икенче көнендә каршыга дошманның танклары тезелешеп килә иде инде. Бер танк безнең янда туктады да, аннан ике кеше чыкты. Берсе старшинаның өр-яңа мылтыгын алып, үлеп яткан солдатның башына атты. Икенчесе минем янга килде. Танкка утыртып, бер кечкенә авылга алып китте. Анда исән калган совет солдатларын җыйганнар иде. Барыбызны бер ишегалдына кертеп яптылар. Шулай итеп, мин әсирлеккә эләктем.

Безне җәяүләп Польшага кадәр алып киттеләр. Польшада безне Идел-Урал легионының өченче батальонына куштылар. Фашистлар чигенгән саен, окопларны казый-казый, көнчыгыш Пруссиягә кадәр барып җиттек. Балтыйк диңгезенә кадәр чигендек. Чигенер урын калмагач, немец солдатларын һәм әсирләрне пароходка төяп алып киттеләр. Минем тирәнрәк казыган чокырым бар иде. Без, өч әсир, шул чокырда качып калдык. Шуннан соң Кызыл армия килеп җитте. Кайсыдыр солдатлар: «Атарга кирәк боларны», – диләр. Командирлары атарга рөхсәт итмәде. Тикшергәннән соң безне запас полкка җибәрделәр, ә аннан 50 нче дивизиягә озаттылар. Дивизия белән Берлинга кадәр барып җиттек.

ТЫЛ ВЕТЕРАНЫ БИБИНУР ГЫЙЛФАНОВА (МӨСЛИМ РАЙОНЫ):

– Бөек Ватан сугышы башланганда миңа ун яшь иде. Безне ашлык суккан җирдән, ындыр табагыннан өйгә кайтармыйча эшләттеләр. Тәүлеккә бер мәртәбә кайнар ризык – борчак боткасы бирәләр иде, ипи юк. Кайчак суы да булмый. Төнлә дә өйгә кайтмыйбыз, эскерт астында йоклыйбыз. Сукырайган әнине карауны күршедә яшәгән бөкре карчыкка тапшырдылар. Сугыш башланган чорда ир-егетләр, яшьләр сугышка киттеләр. Балалар, әниләр, әбиләр – барысының да елап калганы истә. Ир-егетләр атларны куалый. Алар артыннан, елый-елый, балалар йөгерә. Минем әтием инде вафат, тик мин дә башкалар белән йөгерәм. Ул вакытта авылдагы ир-егетләр хәзергеләрдән бик аерыла иде. Барысы да көчлеләр, беләкләре эш белән чыныккан, юан, гәүдәләр – төп кебек. Барысын да каһәр сугыш алды бит, алды... Моның кадәр вәхшилекне, күз яшьләрен минем башка күргәнем булмады. Киләчәк буыннарга да күрергә язмасын!

СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ ХӘТИРӘ САЛИХОВА (КУКМАРА РАЙОНЫ):

– Сугыш башлангач, мине Тәтеш районына окоп казырга җибәрделәр. Ике ай ярымнан авылыма кайттым. 1942 елда, армия яшем тулгач, сугышка алдылар. Арчада комиссия узганда сәламәтлегемнән бер генә гаеп тә тапмадылар. Хәтта, буең кечкенә, дип тә бәйләнмәделәр. Илне дошманнан саклау теләгем зур иде. Башта мине Мәскәү янындагы Химки шәһәрендә радистлыкка укыттылар. Аннан эшелон белән Ленинград фронтына озаттылар. Татарстаннан барлыгы 24 кыз идек. Барыбыз да – татарлар. Без килгәндә, Ленинград инде камалышта иде. Шәһәргә алтмыш чакрым чамасы кала эшелон туктады. Калган юлны үрмәләп бардык. Безне, 24 кызны, һава һөҗүменнән саклану гаскәрләренә билгеләделәр. Төп эшебез – фашист самолетларын шәһәр күгенә үткәрмәс өчен, аэростатлар күтәрү иде. Тревога игълан ителүгә, аларны минут эчендә күтәрәбез, беләк юанлыгы трос кулларны суеп бетерә иде. Ул елларны онытырлык түгел. Ленинградта кап-кара җир иде, халык бөтен үлеп ашап бетергән. Күктә бер карга да, чыпчык та очмый. Безнең хәлләр арурак иде әле, ә шәһәр халкы кәкрәеп-бөкрәеп беткән иде. Уйлап карагыз: 900 көнлек ачлык бит ул!